**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об архивном деле в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
27 ноября 2019 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 20 июля 2017 года № 63-ЗРТ «Об архивном деле в Республике Татарстан» (Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 55 (часть I) следующие изменения:

1) статью 5 дополнить пунктом 6 следующего содержания:

«6) утверждение положения о государственной информационной системе Республики Татарстан в сфере архивного дела и регламента информационного взаимодействия ее пользователей.»;

2) в статье 9:

а) в части 1 слова «экспертно-проверочной комиссией уполномоченного органа исполнительной власти Республики Татарстан в сфере архивного дела,» исключить;

б) дополнить частью $1^1$ следующего содержания:

«$1^1$. Решение вопросов о включении в состав Архивного фонда Республики Татарстан конкретных документов осуществляется экспертно-проверочной комиссией уполномоченного органа исполнительной власти Республики Татарстан в сфере архивного дела в пределах его компетенции.»;

3) статью 22 дополнить частью 5 следующего содержания:

«5. В целях автоматизации архивного дела и повышения качества и эффективности предоставления государственных и муниципальных услуг в этой сфере, в том числе в электронном виде, в Республике Татарстан создается и используется государственная информационная система Республики Татарстан в

сфере архивного дела. Положение о государственной информационной системе Республики Татарстан в сфере архивного дела и регламент информационного взаимодействия ее пользователей утверждаются Кабинетом Министров Республики Татарстан.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
09 декабря 2019 года
№ 95-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында архив эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 27 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында архив эше турында» 2017 елның 20 июлендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:
«6) архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турында нигезләмәне һәм аннан файдаланучыларның мәгълүмат алмашу регламентын раслау.»;

2) 9 статьяда:
а) 1 өлештә «архив эше өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының эксперт-тикшерү комиссиясе тарафыннан» сүзләрен төшереп калдырырга;
б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:
«$1^1$. Татарстан Республикасының Архив фонды составына төгәл документларны кертү турындагы мәсьәләләрне хәл итү архив эше өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының эксперт-тикшерү комиссиясе тарафыннан аның компетенциясе чикләрендә башкарыла.»;

3) 22 статьяга түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:
«5. Архив эшен автоматлаштыру һәм бу өлкәдә дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтү сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, шул исәптән электрон рәвештә, Татарстан Республикасында архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы булдырыла һәм файдаланыла. Архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат

системасы турында нигезләмә һәм аннан файдаланучыларның мәгълүмат алмашу регламенты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 09 декабрь
№ 95-ТРЗ